| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.06.2026 Казан ш № 467

Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүматны һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат рәвешен эш бирүчеләр тарафыннан урнаштыру тәртибен раслау хакында

«Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау турында» 2026 елның 25 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Беркетелгән документларны расларга:

Эш бирүчеләрнең махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен;

махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат формасын.

2. Әлеге боерык 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы — Р.Ф.Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.06.2026 ел № 467 боерыгы белән расланган

**Эш бирүчеләрнең махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен эш урыннарына квота бирү турында» 2026 елның 25 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнгән һәм эш бирүчеләрнең махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен билгели.

2. Эш бирүчеләр ай саен, хисаптан соң килә торган айның 10 нчы числосына кадәр, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең интерактив порталында махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу квотасының үтәлеше турында мәгълүмат урнаштыралар https://portal.tatartrud.ru/EE/ (алга таба - портал).

3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квотаның үтәлеше турындагы мәгълүмат эш бирүчеләр тарафыннан әлеге боерык белән расланган форма буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация системасындагы порталда урнаштырыла.

4. Эш бирүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация системасы аша махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат, квалификацияле электрон имза кулланып, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең рәсми электрон почта адресына яисә кәгазьдә почта элемтәсе ярдәмендә якланган элемтә каналлары аша җибәрелә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.06.2026 ел № 467 боерыгы белән расланган

форма

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлеше турында мәгълүмат**

| |
|---|
| |

хисап чоры

1. Оешманың тулы исеме (шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)):
___________________________________________
2. Салым түләүченең шәхси номеры (ИНН) _____________________________
3. Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) _____________________________________
4. Оешманың урнашкан урыны чикләрендәге адрес (шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны адресы):

4.1. район, торак пункт _____________________________________________
4.2. урам ______________________________________________________________
4.3. йорт, корпус, корылма ________________________________________________
4.4. офис, фатир номеры ________________________________________________
5. Хезмәткәрләрнең хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны:
5.1. район, торак пункт _____________________________________________
5.2. оешманың вәкиллеге, филиалы һәм башка аерымланган структур бүлекчәсе исеме (булган очракта) ____________________________________________
6. Мәгълүмат бирелә торган Татарстан Республикасы мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесе исеме ______________________________________________
7. Хезмәткәрләр саны ______ кеше
8. Алдагы квартал өчен хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны _ _ _ _ кеше[1]
9. Махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә кабул итү өчен квота күләме:
9.1. ____%
9.2. ____ кеше
10. Хисап чорында квота хисабына эшләгән хезмәткәрләр саны барлыгы ____ кеше:

10.1. шулардан махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә урнаштыру турында төзелгән килешүләр кысаларында башка оешмалардагы квота хисабына яисә оешмалар төркеме өчен башка оешма яисә шәхси эшмәкәр белән килешү төзү юлы белән махсус хәрби операциядә катнашучыларны эшкә алу өчен квота үтәлешен тәэмин итүче оешма белән түләүле хезмәт күрсәтү буенча төзелгән шартнамә яисә башка шартнамә кысаларында башка эш бирүчеләрнең хисап чорында квота хисабына эшләгән хезмәткәрләр саны, махсус хәрби

[1] Рәсәй Федерациясенең башка субъектларында урнашкан эш бирүченең вәкиллекләре, филиаллары һәм башка аерым структур бүлекчәләре хезмәткәрләрен исәпкә алмыйча

операциядә катнашучы һәм башка оешма, шәхси эшмәкәр арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе _ _ _ кеше
11. Махсус хәрби операциядә катнашучылар арасыннан инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының гомуми саны _ _ _ берәмлек[2]
12. Хисап чоры ахырына билгеләнгән квотадан артыграк эшләүче махсус хәрби операциядә катнашучылар саны ____ кеше
13. Бирелгән мәгълүматка аңлатмалар[2]________________________________________________

____________________________________________________ __________________________
(эш бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса)) (имза)[3]
"__" ____________ 20__ ел.

[2] Тутыру өчен мәҗбүри түгел
[3] Үз кулы белән яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып имзалана.